ISSN 0868-4545

№11.2009





САЛАВАТ КҮПЕРЕ

БАЛАЛАР ЖУРНАЛЫ
ДЕТСКИЙ ЖУРНАЛ
CHILDREN'S MAGAZINE

Бәйрәм белән, әниеем!

Ләбибуллина
4.02.2010.

САЛАВАТ КҮПЕРЕ

БАЛАЛАР ЖУРНАЛЫ · ДЕТСКИЙ ЖУРНАЛ · CHILDREN'S MAGAZINE

№11(236) — 2009

Журнал 1990 елның
март аеннан бирле чыга.
Журнал основан
в 1990 году.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Баш мөхәррир урынбасары
Нәфис ИСХАКОВ

Бүлек мөхәррирләре
Зилә ЯЗ,
Римма ШӘЙДУЛЛИНА

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Алла АЙСЕНА

Верстка
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Игътибар, күңелле хәбәр! Киләсе санда Яңа елны каршыларга әзерләнәбез.



АНОНСИК

- ӘНИЛӘР БӘЙРӘМЕНӘ МАХСУС СЦЕНАРИЙ. 2-3 нче битләр.
- ТӘМЛЕ СҮЗЛӘР ЯРАТАСЫҢМЫ? 7 нче бит.
- «ПАЗЛ» ҖЫЯРГА ӨЙРӘНӘБЕЗ. 8 нче бит.
- ЙОМШАККАЙГА НӘРСӘ БҮЛӘК ИТИК? 10-11нче битләр.

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече
яшьтәге
мәктәп балалары өчен.

«Салават күпере» журналының
компьютер үзәгендә җыелды һәм
төсләргә бүленде.

Басарга кул куелды 02.11.2009 ел.
Кәгазь форматы 60x90 1/8.
Гарнитура — Футурис. Офсет ысулы белән
басыла. Заказ В-1592. Тираж 8934 данә.


Журналны гамәлгә куючы —
«Татмедиа» ачык акционерлык
җәмгыяте.


Тираж
сертификацияләнгән.
Бәясе килешү буенча.
Индекс 73953.

Санны әзерләүчеләр: З.Хөснияр,
Л.Лерон, Ф.Муллахмәт, З.Яз, М.Галиев,
З.Вакказова, Г.Сабирова.

Безнең адрес: 420012, Казан ш.,
Мөштәри ур., 14 нче йорт.
Тел.: 236-61-98, 236-00-81,
236-61-97, 236-30-01
E-mail: salavatkupere@mail.ru

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм
матбугат министрлыгы тарафыннан 321
номер белән 1994 елның 4 февралендә
теркәлде.

«Идел-Пресс» ачык акционерлар
җәмгыятендә басылды.
Адресы: Казан шәһәре, Декабристлар урамы,
2 нче йорт.



Тышлыкта – Индира Сабирова
кызы Динә белән.
Зилә ЯЗ төшергән
фотосурәт файдаланылды.

© «Салават күпере», 2009 ел

АВТОР
Зиннур ХӨСНИЯР

Әниемнең көләч йөзе

Рәссам Алла АЙСЕНА

– Әни, әни, нигә син гел елмаясың?
– Син янымда булганга елмаям, балам.
– Әни, син нигә гел шат күңелле?
– Син дәү булып үсеп җитәрсең дә әтиең белән әниеңә, кешеләргә гел изгелек кенә кылырсың дип уйлаганга, балам.
– Әни, әни, нигә һаман йөзләрең көләч?
– Шундый дәү, акыллы, әти белән әни сүзен тыңлый торган балам булганга йөзем көләч минем.
– Димәк, синең шат йөзле булуыңа мин сәбәпче?
– Әйе, балам, син сәбәпче...



ӘНИ - мама - mum, mummy ['мам, мамми]

ИЗГЕЛЕК - доброта - kindness ['кайнднэс]

ЕЛМАЮ - улыбка, улыбаться - smile ['смайл]

СӘБӘПЧЕ - причина, повод - reason ['ризэн]

Дускай, Әниләр көне ноябрь аеның 29 нчы көнендә була. Шуңа күрә кулыңдагы өр-яңа «Салават күпере» журналы әниләребезгә багышлана. Әгәр дә син көн саен ярдәмчел, акыллы, сүз тыңлаучан булсаң, дөньядагы иң кадерле, якын кеше – әниебезнең йөзендә, һичшиксез, гел елмаю гына балкып торачак. Онытма, яшь дустым, әниләрнең һәр көне бәйрәм кебек булуы – безнең кулда! Әти-әниеңне сакла, кадерлә, тәүфыйклы бала булып үс!



Бүген әни…

Балалар бакчасында зур бүлмә матур итеп бизәлгән, бизәлеш урман пейзажын хәтерләтә. Кырыйда алтын яфракларга күмелгән агачлар, күзгә куак-үсемлекләр, гөмбәләр үсеп утыра. Бүлмәнең урта бер җирендә – төрле чәчәкләр булып киенгән балалар, музыка яңгырый.

1нче бала: Авырыйм! Бер дә хәлем юк!

2нче бала: Әйе шул, бөтен яфракларыбыз, чәчкәләребез шиңә башлады.

3нче бала: Ни эшләргә икән инде хәзер безгә?

4нче бала: Әйдәгез, бергәләшеп Кояш апа янына барып карыйк. Бәлки, ул безгә берәр киңәшен бирер?!

Балалар озын юл буенча барган сыман, бергәләшеп бүлмәне әйләнәләр. «Мамонтёнок» мультфильмыннан «Песенка мамонтёнка» җырының көе яңгырый. Балаларның каршына кояш булып сары киемгә киенгән, сипкелләр төшергән, бит алмаларын кызарткан тәрбияче апа чыга.

Кояш апа: Хуш киләсез, чәчәкләрем!

Балалар: Без, Кояш апа, урман наратларының зур сәламен, хайваннарның, кош-кортларның изге теләкләрен, бөтен урман дөньясының олы хөрмәтен Сезгә җиткерәбез!

Кояш апа: Рәхмәт, рәхмәт. Тик нишләптер йөзегез качкан, кәефегез дә бик шәп түгел, ахрысы! Берәр борчуыгыз бармы?

Балалар: Әйе шул, кинәт яфрак-чәчкәләребез шиңә башлады. Шуның сәбәбен белмибез. Кояш апа, безгә берәр киңәш бирче.

Кояш апа: Бер дә белмим шул, балакайларым. Мин һәр көн сезне нурларым белән җылытып, назлап торам, сезнең тизрәк үсеп җитүегезне телим. Бәлки, сезгә Болыт абыегызның шифалы яңгырлары җитмидер?!

Балалар яңгыраган көй астына кабат бүлмәне әйләнәләр. Алар зәңгәрсу киемгә киенгән, битенә тамчылар төшергән елап утыручы Болыт абыйны (тәрбияче) күрәләр.

Болыт абый: Сезне миңа нинди юллар алып килде, чәчәкләр? Берәр йомыш белән килгәнсездер әле?! (Кырыс тавыш белән).

Балалар: Борчыганга гафу ит инде, Болыт абый! Беләбез, синең эшең бик күп! Безгә су җитеп бетми, ахрысы, яфрак-чәчкәләребез авырый.

Болыт абый: Сәбәп миндә түгел! Мин өстән барысын да күреп торам: сезгә, бәлки, әниләрегез үпкәләгәндер! Аларга сезнең матур сүзләр белән эндәшүегез, тәртипле, акыллы, тыңлаучан булуыгыз, ярдәмегез җитә микән?!

1нче бала: Әйе шул, без гаепле. Әниләребездән гафу үтенеп, яратуыбыз турында әйтергә кирәк!

Чәчәкләр булып киенгән балалар, әниләре янына йөгереп барып, аларны кочаклыйлар, матур сүзләрен, теләкләрен әйтәләр.

2нче бала: Әйдәгез, без бергә әниләребезгә бүген бәйрәм оештырыйк.


3нче бала: Бәйрәм булса, матур, күңелле булсын! Әниләребезне куандырыйк, биеп, җырлап, шигырь сөйләп күрсәтик!



Рәссам Алла АЙСЕНА

бәйрәме!

Балалар барысы бергә, кулга-кул тотынышып, чәчәкләр биюен яки башка биюне башкаралар. Аларга Кояш апа һәм Болыт абый да кушыла. Бию тәмамлангач, балалар бер-бер артлы шигырь сөйли башлыйлар.




1нче бала: Иртүк торып битен юган,
Кем уяткан Ләйләне?
Уятмаган, үзе торган –
Бүген әни бәйрәме.

2нче бала: Пәрдәләрне ачып куйды,
Көн кояшлы, әй ямьле!
Яхшы булсын, балкып торсын –
Бүген әни бәйрәме!

3нче бала: Өстәл өстен кат-кат сөртте,
Җәйде ап-ак җәймәләре.
Чиста булсын, пөхтә булсын –
Бүген әни бәйрәме!

4нче бала: Күмәкләшеп без дә, дуслар,
Җырлап алыйк әйдәле.
Котлы булсын! Гөрләп торсын
Әниләрнең бәйрәме!

Көй агыла. «Кояш гомере» дигән җыр яңгырый (Гөлшат Зәйнашева шигыре).



Балалар: Бер кыз бала җыр чыгарган
Багышлап әнисенә.
Икәү бергә җырлыйк, диеп,
Өйрәткән энесенә:
«Кояш, кояш мәңге балкый,
Мәңге нур сибә.
Кояш гомере телим мин
Әнием сиңа...»

Балалар: Әниләр, Сезгә һәрвакыт яныбызда булганыгыз өчен зур рәхмәт! Әни җылысы – бөтен авырулардан дәва ул. Бүтән беркайчан да сезнең кәефегезне төшермәбез!

Кояш апа белән Болыт абый чыга.


Кояш апа белән Болыт абый: Кадерле балалар, бүген – Әниләр көне! Кадерле чәчәкләр, әниләрнең һәр көне бәйрәм кебек булуы – безнең кулда! Сез көн саен ярдәмчел, акыллы, сүз тыңлаучан булсагыз, дөньядагы иң кадерле, якын кешеләр – әниләребезнең йөзендә, һичшиксез, гел елмаю гына балкып торачак.

Тәмам.

Зилә ЯЗ.
Сценарийда Сәҗидә СӨЛӘЙМАНОВА
шигыре файдаланылды.

Рәссам Алла АЙСЕНА











«Әни» сүзе


«Әни» диеп язып куйдым
Яңа яуган ак карга.
Таптамагыз!
Һич ярамый
«Әни» сүзен таптарга.

Әни белән сөйләшү

– Әни, әни!
Дөнья нигә матур?
– Син көлгәнгә,
кояш көлгәнгә.
– Һәр таң саен
ник аллана кояш?
– Төшмәсен дип
җиргә күләгә.

Ипи һәм әни

Ипи сала әни,
миче кайнар.
Бисмиллалы монда
һәр күмәч.
Таба кызган,
камыр шундый уңган –
Әниемнең йөзе шат,
көләч!



Дускай, әйдә, бергәләшеп әниләребезгә бүләк-открытка ясыйк.
Журналның әлеге битен ипләп кенә кисеп алырга һәм икегә бөкләргә кирәк.

Гөлшат
ЗӘЙНАШЕВА

Кояш гомере

Бер кыз бала җыр чыгарган,
Багышлап әнисенә.
Икәү бергә җырлыйк диеп,
Өйрәткән энесенә:

«Кояш, кояш
Мәңге балкый,
Мәңге нур сибә.
Кояш гомере телим мин,
Әнием, сиңа!»

Җырны чишмәләр ишеткән,
Кошлар отып алганнар.
Сандугачлар һәм тургайлар
Матур көйгә салганнар.


Кушыл син дә,
Җырлыйк бергә,
Яңа матур җыр тусын.
Җирдә әниләр кояштай
Озын гомерле булсын.





Уңышлар сиңа!

Монда әниеңнең
фотосурәтен ябыштырып куй!



Әнием!





Тәмле сүзләр



Мин яраткан иң татлы сүз:
– Ул – *мәми*.
Мәмидән дә тәмлерәк сүз:
– Ул – *әни*.
Әни белән әти өчен:
– Мин – *бәби*.
Ә бәбигә иң баллы сүз:
– *Әти-әни...*

Сизәсеңме, ошбу тәмле сүзләрне әйтүгә синең авыз эчең баллана башлады. Ә баллы авыздан әти-әнигә карата бары тик татлы җөмләләр генә чыга:

– Рәхмәт! Бик зур рәхмәт! Ходай кабул итсен!

– Исән-саумы? Ни хәлләрең бар?

– Сау-сәламәт бул! Алланың рәхмәте яусын! Мин сине бик яратам!

Тәмле сүзләр белән иң нәни чактан ук иркәләп сөюче, дөньядагы иң сөйкемле зат – әниебезгә Ходай рәхмәте яусын... Амин! Шулай булсын!

Рәссам Алла АЙСЕНА

ӘТИ - папа - dad, daddy ['дэдъ, дэддьи]
ТӘМЛЕ - вкусный - delicious [дэли'шэс]
БАЛЛЫ - сладкий - sweet ['суитъ]
РӘХМӘТ - спасибо- thank you, thanks ['фэнк ю, фэнкс]
НӘНИ - маленький - little one ['литтл уан]
ХОДАЙ - бог - god ['гадъ]



Puzzle




Дускай, без сиңа «Пазл» дип атала торган яңа уен тәкъдим итәбез. Башта бу вак өчпочмакларны кис, шуннан соң аларны, үрнәккә карап, бер-берсенә туры китереп, катыргы кәгазьгә ябыштырып куй. Нәтиҗәдә әни һәм бәби юлбарыс рәсеме килеп чыгарга тиеш. Уңышлар!




Валера ФОМИН төзеде.





Башкатыргычлар

Көзге салкыннар килеп җитте. Әйдә, Елмай белән Шүркәгә бирелгән башкатыргычтан киемнәр эзләп карыйк. Моның өчен шакмактагы хәрефләр ярдәмендә өстән-аска, астан-өскә, сулдан-уңга, уңнан-сулга язылган сүзләрне табып, сызарга кирәк. Рәсемдәге киемнәрнең кайсыларын кызлар, кайсын егетләр кия?








К	У	Л	Ы	К	П	Ә	Л	Т	Ә
Ү	Я	К	К	Ә	Ш	Ф	Б	И	Я
Л	М	Ә	И	Т	А	Р	А	К	Л
И	Т	Е	Ч	А	Л	Ф	Л	Й	Ә
У	Т	К	Ф	У	Б	А	К	К	Ә
Н	Ш	Ә	Л	Т	А	Ү	П	Ә	Л
А	К	Л	О	Б	Р	Ш	Г	А	Л
А	Л	Ъ	Я	Ч	И	К	У	Т	С
Р	А	С	П	К	Т	Е	О	Е	К
А	Ф	А	Н	Ы	Ч	К	Б	А	Ш









Рәссам Валера ФОМИН












Ләбиб ЛЕРОН

Йомшаккайның туган көне

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ





1 Йомшаккай туган көненә дусларын чакырды.



2 Шүркә кунакка барырга җыенды.



3 Кинәт Шүркә каршында Убырлы карчык пәйда булды.



4 Шүркә Убырлыга: «Себеркене бүләк итмиләр!» – диде.



5 Бу вакытта Елмай оекбаш бәйләп утыра иде.



6 Елмай янында Убырлы пәйда булды.



7 Малай-Шалай Йомшаккайга футбол тубы бүләк итәргә булды.



8 Йомшаккайның дуслары Убырлыдан көч-хәл белән арындылар.



9 Дуслар әниләренә әйтеп тормыйча гына кунакка киттеләр.



10 Бик нык кайгыга төшкән әниләр балаларын Йомшаккай өеннән эзләп таптылар.



Тәрбия дәресе

Ана йөрәге

(М.Скребцова әкияте буенча)

Урманның нәкъ уртасында искиткеч матур Ана Каен һәм аның өч кызчыгы – зифа буйлы ап-ак каенкайлар – шау-гөр килеп үсеп утыралар. Ана газиз балаларын салкын җил-яңгырдан, җәйге эсселектән гел саклый икән. Үзенең киң ботакларын җәеп, кызчыкларын кочагына алып иркәли, назлый. Каенкайлар көннән көн көлешә-көлешә үсә, матурлана баралар. Кадерле әниләре яннарында – моңсуланырга сәбәп юк!

Көннәрдән бер көнне урманда көчле давыл чыга. Кинәт күк йөзе караңгыланып китә дә, яшенле салкын яңгыр ява башлый. Кечкенә каенкайлар, бик куркып, әниләренең күкрәгенә сыеналар.

Ана Каен, нәни кызчыкларын тагын да көчлерәк кочаклап, йомшак тавыш белән эндәшә:



БОТАК - ветка - branch ['бранч]
КОЧАК - объятия - embrace [имбрэ'йс]
ШАТЫРДАУ - треск - crash ['крэш]
ТӘКӘББЕР - упрямый - stubborn ['стаббон]
КӘҮСӘ - ствол - trunk ['търанк]
МҮК - мох - moss ['мас]



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



– Мин бит бу урманда – иң биек, иң нык агач. Минем кочагымда сезгә усал җил дә, салкын яңгыр да, куркыныч яшен дә тия алмас, – ди.

Ана Каен бу сүзләрне әйтеп бетергәч үк, урманны куркыныч шатырдау тавышы яңгырата. Явыз яшеннең утлы угы Ана Каен йөрәгенә кадала да яндыра башлый. Тик Каен аны җиргә аударырга тырышкан яшенгә дә, җил-давылга да, тәкәббер салкын яңгырга да бирешми, нәни кызчыкларын кочагыннан чыгармый. Күккә ялтырап кояш чыккач кына, Ана Каен кәүсәсе тетрәп куя.

– Газиз балакайларым, хәлем бетте, кәүсәм җиргә авыша, – ди Каен. – Тик мин сезне ташламыйм. Бераздан кәүсәмне мүк һәм төрле үләннәр капласа да, аның эчендә кайнар йөрәгемнең тибешен ишетерсез, – дип Ана Каен соңгы сүзләрен әйтә һәм әкрен генә җиргә авып төшә.

Бүген бу урында зифа буйлы өч каен үсеп утыра. Аларны һаман да үлән һәм мүк белән капланган Ана Каен кәүсәсе саклый. Урманга барып, бу өч каенга очрасагыз, Ана Каен кәүсәсе янында ял итегез. Шунда аның йомшаклыгын тоярсыз, ә күзләрне йомып, тынлыкта калсагыз, Ана Каен йөрәге тибешен ишетеп була.

Р. ШӘЙДУЛЛИНА тәрҗемәсе.



ӨЧ НӘНИ КАЕНКАЙ ӘНИСЕЗ НИЧЕК ЯШӘР МИКӘН?

ДУСКАЙ, СИН НИЧЕК УЙЛЫЙСЫҢ, НИ ӨЧЕН ӘНИЛӘР ГЕЛ ҮЗ БАЛАЛАРЫН ЯКЛЫЙ ИКӘН?

Ә СИН ӘНИЕҢНЕ АВЫР ЧАКТА НИЧЕК ЯКЛАРСЫҢ?

СИНЕҢ ӘНИЕҢ НИНДИ? АНЫҢ КҮҢЕЛЕНДӘ БУЛГАН МАТУР СЫЙФАТЛАРНЫ САНАП КАРА ӘЛЕ.










Бүген без Казан шәһәренең Вахитов районында урнашкан 212 нче «Әкият» балалар бакчасында кунакта. Балалар журналыбызны яратып укыйлар, рәсем-шигырьләрен җибәреп торалар. Дуслыгыбыз озын гомерле булсын, «Әкият»кәй!













Эмилия ГЫЙЛӘҖЕВА, 7 яшь.
Азнакай.

ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ ӨЧЕН ИҢ ӘЙБӘТ ВАКЫТ!!!
ИНДЕКС – 73953.
Ярты елга язылу бәясе – 114 сум.

Әни

Иң гүзәл кеше –
Әнием минем.
Иң уңган кеше –
Әнием минем.
Иң матур кеше –
Әнием минем!

Җылы, иркә наз –
Әнидә генә.
Татлы, назлы сүз –
Әнидә, беләм!

Яратам аны,
Һәрчак булышам,
Картайтмас өчен
Мин бик тырышам.

Гүзәл ВИЛДАНОВА, 10 яшь.
Түбән Кама.

Салават күпере

Почта России

АБОНЕМЕНТ на ~~газету~~ журнал 73953 (индекс издания)

Салават күпере
(наименование издания) количество комплектов:

на 2010 год по месяцам:

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12

Куда
(почтовый индекс) (адрес)

Кому
(фамилия, имя,отчество)

Салават күпере

пв	место	литер

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА
на ~~газету~~ журнал 73953 (индекс издания)

Салават күпере
(наименование издания)

Стои-мость	подписки	____руб.____коп.	количество комплектов:
	пере-адресовки	____руб.____коп.	

на 2010 год по месяцам:

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12

Куда
(почтовый индекс) (адрес)

Кому
(фамилия, имя,отчество)



Дәресне Гузәлия ОШКИНА
белән Румия СӘЛИМУЛЛИНА
алып бара.

a map [э'мэп]
карта




milk ['милк]
сөт



Mm

a mouse [э'маус]
тычкан



a mat [э'мэт]
коврик





M M M ____________________

m m m ____________________

Рәссам Алла Айсена

Aa Bb Cc Dd Ee Ff Gg Hh Ii Jj Kk Ll M



Мин бит бу!



Кому
Куда г.Казань, ул.Муштари, 14.
420012



Ислам, 1 яшь 6 ай
– Иртән торгач, «Бисмилла»,
дим.
Кичләрен дә «Бисмилла», дим...
Ислам нуры күңелләрне
Гел яктыртып торсын... Амин!
Әтнә, Олы Әтнә



Зилә, 10 яшь
– Туй күлмәген киеп, менә
Яныгыздан үтәмен...
«Нишләп йөри бу?» –
димәгез,
Киявемне көтәмен!
Кукмара, Состамак




Булат, 3 яшь
— Кулларымда гармуным —
Уйнарлык дәрт бар минем:
Өздерепләр уйныйм әле
Татарымның бар моңын!
Югары Ослан, Октябрь бистәсе



Атлас, 2 яшь
Рөстәм, 1 яшь 6 ай
— Утырабыз әле менә
Бер кәнәфидә икәү:
Берәр эшкә түрә итеп
Безне алмаслар микән?
Кукмара, Байлангар

СЕЗДӘН ХАТЛАР КӨТӘБЕЗ!



Канатлы талант



«Сәлам, дускай! Исемем — Азалия. Миңа 6 яшь. 3 яшемнән алып А.Ю.Романенконың «Пестрая компания» ансамблендә җыр һәм бию осталыгына төшендем, «Ученый малыш» мәктәбендә язу, математика, инглиз теле белеме нигезләрен өйрәндем. Хәзер «Вдохновение» мәктәбендә шөгыльләнәм. Биергә, рәсем ясарга, әниемә өй эшләрендә ярдәм итәргә бик яратам. Киләчәктә үземне теш табибы яки балерина итеп күрәм».

Азалия ХИСАМИЕВАның уңышлары:

- Лауреат I Межрегионального фестиваля эстрадного искусства «Песня Планеты-2008» в г.Казани.
- Дипломант IX республиканского фестиваля эстрадного искусства «Созвездие-Йолдызлык» в номинации «Вокал-соло» в г.Казани, 2009 г.
- Дипломант Межрегионального эстрадно-вокального конкурса «Молодые голоса нефтеграда» в г.Альметьевске, 2009 г.
- Во II Республиканском конкурсе красоты и талантов «Маленькая принцесса Татарстана» завоевала титулы «Мини-Мисс Татарстан» и «Мини-Мисс фотомодель», 2009 г.
- Обладательница титула «Маленькая Мисс Жемчужина» на Международном фестивале «Маленькая Мисс Мира» в Турции, 2009 г.

Азалия Хисамиева



